МИНИСТЕРСТВО ЗДРАВООХРАНЕНИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

28.02.2022 г. Казань № 500

Татарстан Республикасында өлкән халыкка кискен коронар синдром вакытында медицина ярдәме күрсәтүне оештыру турында

«Йөрәк-кан тамырлары авырулары белән авыручыларга медицина ярдәме күрсәтү тәртибен раслау турында» 2012 елның 15 ноябрендәге 918н номерлы Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасының өлкән халкына кискен коронар синдром вакытында медицина ярдәме күрсәтүне оештыруны камилләштерү максатларында, б о е р а м:

1. Раслarga:

1.1. Кардиохирургия тыкшынуларын үткәрү өчен үз структурасында диагностиканың һәм дәвалауның рентгеноэндоваскуляр методлары бүлеге булган, (алга таба – ПЧКВ-үзәк) Татарстан Республикасы медицина оешмаларына беркетергә тәкъдим ителгән муниципаль берәмлекләрне (әлеге боерыкка Кушымта № 1);

1.2. Кискен коронар синдром белән пациентларга медицина ярдәме күрсәтүне оештыру регламенты (алга таба – Регламент) (әлеге боерыкка Кушымта № 2).

2. Кискен коронар синдромы билгеләре булган пациентларны (алга таба – ОКС) үз вакытында ачыклау, ПЧКВ-үзәккә җибәрү һәм эвакуацияләүне оештыру өчен җаваплылыкны Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасын гамәлгә ашыруда катнашучы медицина оешмалары (алга таба – медицина оешмалары) җитәкчеләренә йөкләргә.

3. Амбулатор-поликлиника шартларында медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмалары җитәкчеләренә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

3.1. Беркетелгән халык арасында ОКС билгеләренең беренче билгеләренә, аның үсеш риск факторларына, беренчел һәм икенчел профилактика принципларына сакчыллык формалаштыру, шулай ук Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылган Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Электрокардиограммада ST сегменты күтәрелеше белән кискен коронар синдром», «Электрокардиограммада ST сегменты күтәрелмичә кискен коронар синдром» клиник рекомендацияләре (алга таба – клиник

рекомендацияләр) нигезендә ОКС вакытында медицина ярдәме күрсәтү буенча даими санитар-агарту эшләрен алып бару https://cr.minzdrav.gov.ru/ ;

3.2. Кичектергесез медицина ярдәме күрсәтелгәннән соң клиник рекомендацияләр нигезендә ОКС белән пациентларны ПЧКВ-үзәккә җибәрү;

3.3. Клиник рекомендацияләр нигезендә ОКСны дәвалау өчен дару препаратларының даими булу;

3.4. Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Өлкәннәргә диспансер күзәтүен үткәрү тәртибен раслау турында» 2019 елның 29 мартындагы 173н номерлы боерыгы белән расланган Өлкәннәргә диспансер күзәтүен үткәрү тәртибе нигезендә, миокард инфарктын, стабиль булмаган стенокардияне кичергән пациентларга, диспансер күзәтү;

3.5. Пациент турында мәгълүматны кан әйләнеше системасы авырулары регистрына (алга таба – БСК регистрына), «Баш мие кан әйләнешенең кискен бозылуын, миокард инфарктын кичергән, шулай ук аортокоронар шунтлау, стентлау белән коронар артерияләрнең ангиопластикасы һәм йөрәк-кан тамырлары авырулары буенча катетер абляциясе башкарылган затларны амбулатор шартларда тәэмин итү өчен Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының дару препаратлары исемлеген раслау турында» Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының 2021 елның 24 сентябрендәге боерыгы һәм «Татарстан Республикасында кан әйләнеше системасы авырулары регистрын алып бару турында» Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 31.01.2020 № 163 боерыгы нигезендә ташламалы дару препаратларына рецептлар яздыру.

4. Стационар шартларда медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмалары җитәкчеләренә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

4.1. Госпитальгә кадәр медицина ярдәме күрсәтү өчен тромболитик препаратларның, шулай ук клиник рекомендацияләр нигезендә ОКСны дәвалау өчен башка дару препаратларының даими булу;

4.2. ОКС белән пациентларны, кичектергесез медицина ярдәме күрсәткәннән соң, тромболитик терапия – күрсәткечләре буенча клиник рекомендацияләр нигезендә, ПЧКВ-үзәккә җибәрү;

4.3. Стационар дәвалауда башка авыру белән булган пациентны ОКС ачыкланган очракта, ПЧКВ-үзәккә вакытында күчерү;

4.4. Гемодинамик һәм\яки электр тотрыксызлыгы белән (кардиоген шок, үпкәләр шешүе, ритмның гомер өчен куркыныч тудыручы бозылулары, йөрәк-үпкә реанимациясе) өзлеккән, кичектергесез медицина ярдәме күрсәтү, халәтне тотрыкландыру һәм алга таба ПЧКВ-үзәккә күчерү өчен, ОКС белән пациентны госпитализацияләү;

4.5. ОКС белән пациент турында мәгълүматны «Йөрәк-кан тамырлары авырулары» Вертикаль-интеграцияләнгән медицина мәгълүмат системасына (Вертикально-интегрированная медицинская информационная система «Сердечно-сосудистые заболевания») (алга таба – ВИМИС «ССЗ») кертү;

4.6. Әлеге боерыкның 4.4 пункты нигезендә, өзлеккән ОКС белән пациентны госпитализацияләү очрагында, «Төбәкара клиник-диагностика үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе базасында Кан әйләнеше системасы авырулары булган пациентларга медицина ярдәмен күрсәтүне мониторинглауның

һәм координацияләүнең республика үзәгенә (алга таба – БСК үзәге) тәүлек буе режимында 8 (843) 291-10-01 телефоны буенча пациентны алып баруның алга таба тактикасы буенча рекомендацияләр алу максатында ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү үзәгенә кичекмәстән хәбәр итү;

4.7. Өзлеккән ОКС булган пациентны госпитализацияләү очрагында яки госпитализацияләнгән пациентларда ОКС билгеләрен ачыклаганда, әлеге боерыкның Кушымта № 3 нигезендә форма буенча әлеге боерыкның п. 4.3. и 4.4. нигезендә БСК үзәгенә электрон почта адресына consultationicdc@tatar.ru, шулай ук Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының баш штаттан тыш белгеч-кардиологы (З.Ф.Ким) электрон почта адресына cardiootchet@yandex.ru атналык мәгълүмат бирү;

4.8. Стационар шартларда ОКСтан үлгән пациентлар турында ай саен мәгълүмат бирү, әлеге боерыкка Кушымта № 5 нигезендә ViPNet сак астына алынган элемтә каналы буенча БСК үзәгенә АП 657 абонент пункты, шулай ук электрон почта адресына gklb7kzn@rmiac.ru (сак астына алынган канал) хисаптан соң килүче айның 5 числосына кадәр.

5. Ашыгыч, шул исәптән ашыгыч махсуслаштырылган, медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмалары җитәкчеләренә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

5.1. Госпитальгә кадәр медицина ярдәме күрсәтү өчен тромболитик препаратларның, шулай ук клиник рекомендацияләр нигезендә ОКСны дәвалау өчен башка дару препаратларының даими булу;

5.2. ОКС белән пациентларны, кичектергесез медицина ярдәме күрсәткәннән соң, тромболитик терапия – күрсәткечләре буенча, әлеге боерыкка Кушымта № 1 нигезендә, ПЧКВ-үзәккә эвакуацияләү;

5.3. Гемодинамик һәм\яки электр тотрыксызлыгы белән (кардиоген шок, үпкәләр шешүе, ритмның гомер өчен куркыныч тудыручы бозылулары, йөрәк-үпкә реанимациясе) катлаулы ОКСДАН, үз составында реанимация бүлеге булган якындагы медицина оешмасына, кичектергесез медицина ярдәме күрсәтү, халәтне тотрыкландыру һәм алга таба ПЧКВ-үзәккә күчерү өчен ОКС белән пациентны эвакуацияләү;

5.4 ОКС белән пациент турында мәгълүматны ВИМИС «ССЗ»га кертү.

6. Стационар шартларда беренчел медик-санитар ярдәм һәм медицина ярдәмен күрсәтүче медицина оешмалары белән үзара хезмәттәшлек өчен җаваплылыкны әлеге боерыкка Кушымта № 1 нигезендә ОКС билгеләре булган пациентларга медицина ярдәме күрсәткәндә үз составында ПЧКВ-үзәкләре булган медицина оешмалары җитәкчеләренә йөкләргә: «Төбәкара клиника-диагностика үзәге» ДАССУ (Р.Н. Хәйруллин), «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» ДАССУ (Р.Ф. Шәвәлиев), «Казан (Идел буе) федераль университеты» ЮБ ФДБМУ МСЧ (С.А. Осипов), Казан шәһәре «7нче Шәһәр клиник хастаханәсе» ДАССУ (А.М. Делян), Чаллы шәһәре «Ашыгыч медицина ярдәме хастаханәсе» ТР ДАССУ (М.Ф. Мөхәмәдиев), «Әлмәт районара күппрофильле хастаханәсе» ДАССУ (Г.А. Шәмсеева), «Түбән Кама үзәк район күппрофильле хастаханәсе» ДАССУ (М.Х. Мостафин) (алга таба – ПЧКВ-үзәкләре җитәкчеләре).

7. ПЧКВ-үзәкләре җитәкчеләренә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

7.1. Әлеге боерыкның Кушымталары № 1, 2 нигезендә, ОКС билгеләре булган пациентларга, шулай ук гамәлдәге клиник рекомендацияләр нигезендә ОКС белән пациентларның мөстәкыйль рәвештә медицина ярдәме сорап мөрәҗәгать иткән пациентларга көн саен тәүлек буе кичектергесез медицина ярдәме күрсәтүне оештыру;

7.2. Клиник рекомендацияләр нигезендә күрсәтмәләре булган пациентларны әлеге боерыкның Кушымталары № 1, 2 нигезендә коронар стентлауга һәм башка кардиохирургия тыкшынуларына сайлап алу һәм җибәрү;

7.3. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының профильле баш штаттан тыш белгечләре, шулай ук Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы федераль дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләре белән телемедицина консультацияләрен үткәрү;

7.4. ПЧКВ-үзәктән чыккан көнне БСК регистрына ОКС кичергән пациентлар турында мәгълүмат кертү;

7.5. ОКС кичергән пациентлар турында мәгълүматны үз вакытында ВИМИС «ССЗ»га тапшыру;

7.6. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «Татарстан Республикасы медицина оешмаларының кураторлыгын оештыру турында» 21.08.2020 ел, № 1379 боерыгы нигезендә, ОКС диагностикасы һәм дәвалау мәсьәләләре буенча ведомствога караган медицина оешмаларының медицина персоналының белемнәрен һәм күнекмәләрен даими күтәрү;

7.7. Әлеге боерыкның Кушымта № 4 нигезендә ОКС белән пациентларның кергән саны турында айлык мәгълүматны БСК үзәгенә электрон почта адресына бирү consultationicdc@tatar.ru, шулай ук Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының баш штаттан тыш белгеч-кардиологына (З.Ф. Ким) электрон почта адресына cardiootchet@yandex.ru хисаптан соң килүче айның 5 числосына кадәр арта баручы нәтиҗә белән бирү;

7.8. ПЧКВ-үзәктә ОКСдан үлгән пациентлар турында ай саен мәгълүмат бирү, әлеге боерыкка Кушымта № 5 нигезендә ViPNet сак астына алынган элемтә каналы буенча БСК үзәгенә АП 657 абонент пункты, шулай ук электрон почта адресына gklb7kzn@rmiac.ru (сак астына алынган канал) хисаптан соң килүче айның 5 числосына кадәр;

7.9. Татарстан Республикасы халкына югары технологияле кардиохирургия ярдәме күрсәтү буенча айлык мәгълүматны әлеге боерыкның Кушымта № 6 нигезендә БСК үзәгенә электрон почта адресына бирү consultationicdc@tatar.ru, шулай ук Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының баш штаттан тыш белгеч-кардиологына (З.Ф. Ким) электрон почта адресына cardiootchet@yandex.ru хисаптан соң килүче айның 5 числосына кадәр арта баручы нәтиҗә белән бирү.

8. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының баш штаттан тыш белгечләренә: кардиологка (З.Ф. Ким), рентгенэндоваскуляр диагностика һәм дәвалау буенча (М.Ю. Володюхин), йөрәк-кан тамырлары хирургиясе буенча (Р.К. Джорджикия) ОКС белән пациентларны диагностикалау һәм дәвалау мәсьәләләрендә беренчел медик-санитар ярдәм күрсәтүче медицина оешмалары, стационар шартларда медицина ярдәмен күрсәтүче медицина оешмалары, ПЧКВ-

үзәкләр эшчәнлеген координацияләүне тәэмин итәргә.

9. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «Татарстан Республикасында өлкән халыкка кискен коронар синдром вакытында кичектергесез медицина ярдәмен оештыру турында» 2020 ел, 12 август, 1310нчы боерыгы үз көчен югалткан дип санарга.

10. Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрының беренче урынбасары А.Р. Абашевка йөкләргә.

Министр М.Н.Садыйков

ТР Сәламәтлек саклау
министрлыгының
28.02.2022 № 500 боерыгына
Кушымта № 1

Кардиохирургия тыкшынуларын үткәрү өчен үз структурасында диагностиканың һәм дәвалауның рентгеноэндоваскуляр методлары бүлеге булган, Татарстан Республикасы медицина оешмаларына беркетергә тәкъдим ителгән муниципаль берәмлекләре

| Беркетелгән территорияләр исемлеге | Медицина оешмаларының атамасы (ЧКВ үткәрү өчен) | Медицина оешмаларының атамасы (кардиохирургия тыкшынуларын үткәрү өчен) |
|---|---|---|
| Аксубай районы;<br>Алексеевск районы;<br>Әлки районы;<br>Әтнә районы;<br>Балтач районы;<br>Кукмара районы;<br>Лаеш районы;<br>Нурлат районы;<br>Балык Бистәсе районы;<br>Саба районы;<br>Спас районы;<br>Теләче районы;<br>Чистай районы | «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» ДАССУ | «Төбәкара клиник-диагностика үзәге» ДАССУ |
| Апас районы;<br>Яшел Үзән районы;<br>Кама Тамагы районы;<br>Тәтеш районы;<br>Казан шәһ.:<br>Вахитов районы;<br>Совет районы, Н.Рахлин ур., 5 адресы буенча урнашкан «Медицина диагностик үзәге» ЖЧҖ филиалы хезмәт күрсәтү территориясен дә кертеп (Азино2, Танкодром, Дәрвишләр бистәсе, Нагорный бистәсе микрорайоннарыннан һәм «8нче номерлы Шәһәр сырхауханәсе» ДАССУ 3 терапия бүлегенә | «Казан (Идел буе) федераль университеты» ЮБ ФДАМУ МСЧ | «Казан (Идел буе) федераль университеты» ЮБ ФДАМУнең МСЧ |

| | | |
|---|---|---|
| беркетелгән территориядән тыш);<br>Киров районы | | |
| Арча районы;<br><br>Казан:<br>Совет районы: Азино-2 микрорайоны, «20нче шәһәр сырхауханәсе» ДАССУ медицина хезмәте күрсәтү өчен беркетелгән территория;<br>Танкодром, Казан шәһәренең «Профессор К.Ш.Зыятдинов исемендәге 18нче Үзәк шәһәр клиник хастаханәсе» ДАССУ 2нче сырхауханә бүлегенә медицина хезмәте күрсәтү өчен беркетелгән территория;<br>Идел буе районы | «Төбәкара клиник-диагностика үзәге» ДАССУ | «Төбәкара клиник-диагностика үзәге» ДАССУ |
| Буа районы;<br>Югары Ослан районы;<br>Биектау районы;<br>Чүпрәле районы;<br>Кайбыч районы;<br>Питрәч районы;<br><br>Казан:<br>Совет районы: Дәрвишләр бис., Нагорный бис., «8нче шәһәр сырхауханәсе» ДАССУ 3 терапия бүлегенә медицина хезмәте күрсәтү өчен беркетелгән территория, «Ситидок-Эксперт Казан» ҖЧҖ;<br>Яңа Савин районы;<br>Авиатөзелеш районы;<br>Мәскәү районы | «7нче шәһәр клиник хастаханәсе» ДАССУ, Казан шәһ. | «Төбәкара клиник-диагностика үзәге» ДАССУ |
| Яр Чаллы шәһәре;<br>Әгерҗе районы;<br>Актаныш районы;<br>Алабуга районы;<br>Мамадыш районы;<br>Менделеевск районы;<br>Минзәлә районы;<br>Тукай районы | «Ашыгыч медицина ярдәме хастаханәсе» ТР ДАССУ, Яр Чаллы шәһ. | «Ашыгыч медицина ярдәме хастаханәсе» ТР ДАССУ, Яр Чаллы шәһ. |

| | | |
|---|---|---|
| Әлмәт шәһәре,<br>Әлмәт районы;<br>Азнакай районы;<br>Баулы районы;<br>Бөгелмә районы;<br>Зәй районы;<br>Лениногорск районы;<br>Мөслим районы;<br>Яңа Чишмә районы;<br>Сарман районы;<br>Ютазы районы;<br>Чирмешән районы | «Әлмәт районара күппрофильле хастаханәсе» ДАССУ | «Әлмәт районара күппрофильле хастаханәсе» ДАССУ |
| Түбән Кама шәһәре,<br>Түбән Кама районы | «Түбән Кама үзәк район күппрофильле хастаханәсе» ДАССУ | «Төбәкара клиник-диагностика үзәге» ДАССУ |

*Искәрмә:* кардиохирургия клиникаларының берсендә коронар шунтлауны уздыруның техник мөмкинлеге булмаганда, пациент маршрутлаштыруны үтәмичә башка кардиохирургия клиникасына җибәрелергә тиеш.

ТР Сәламәтлек саклау
министрлыгының
28.02.2022 № 500 боерыгына
Кушымта № 2

## Кискен коронар синдром белән пациентларга медицина ярдәме күрсәтүне оештыру регламенты

### I. Гомуми нигезләмәләр

Әлеге регламент кискен коронар синдром (алга таба – ОКС) белән пациентларга медицина ярдәме күрсәтүне оештыру алгоритмын һәм ОКС белән пациентларны тиешле дәрәҗәдәге медицина оешмаларына маршрутлаштыру тәртибен Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылган https://cr.minzdrav.gov.ru/ Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Йөрәк-кан тамырлары авырулары белән авыручыларга медицина ярдәмен күрсәтү тәртибен раслау турында» 2012 елның 15 ноябрендәге 918н номерлы боерыгы, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Электрокардиограмманың ST сегменты күтәрелеше белән кискен коронар синдром», «Электрокардиограмманың ST сегменты күтәрелмичә кискен коронар синдром» клиник рекомендацияләр (алга таба – клиник рекомендацияләр) нигезендә билгели.

### II. Кискен коронар синдром белән пациентларга медицина ярдәме күрсәтүне оештыру алгоритмы

1. ОКС белән барлык пациентларны кардиохирургия тыкшынуларын үткәрү өчен үз структурасында диагностиканың һәм дәвалауның рентгеноэндоваскуляр методлары бүлеге булган, (алга таба – ПЧКВ-үзәк) Татарстан Республикасы медицина оешмаларына кичекмәстән җибәрү.

2. ПЧКВ-үзәкнең кабул итү бүлеге дәрәҗәсендә рискны стратификацииялэгәннән соң түбән риск ST сегменты күтерелешсез (госпитализация чорында коронароангиографияне үткәрүне таләп итми торган) ОКС белән пациентларны, территориаль беркетелү нигезендә – билгеләнгән диагноз һәм ПЧКВ-үзәк кардиологы рекомендацияләре белән Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасын гамәлгә ашыруда катнашучы медицина оешмаларына маршрутлаштыру мөмкин.

3. Башка профильдәге медицина оешмасында госпитализацияләү чорында пациентның ОКС үсеше булса, клиник рекомендацияләр белән билгеләнгән сроклар нигезендә, ПЧКВ-үзәк белән килешеп, пациент ПЧКВ-үзәккә күчерелергә тиеш (медицина оешмасының урнашу урыны буенча маршрутлаштыру нигезендә).

*Искәрмә:*

* Кискен коронар синдромына түбәндәгеләр керә: ЭКГда ST сегменты күтәрелеше белән миокард инфаркты яки Гис бәйләмәнең сул яки уң аягында кискен барлыкка килгән миокард инфаркты; ST сегменты күтәрелмичә миокард инфаркты; тотрыксыз стенокардия: беренче тапкыр барлыкка килгән, артучы, инфарктан соң иртә килгән, тын стенокардия.

А. ST сегменты күтәрелеше белән кискен коронар синдром

1. Тромболитик терапияне (алга таба – ТЛТ) каршы күрсәтмәләре булмаганда, ST сегменты күтәрелеше белән һәм тәнне кадап тишү белән коронар тыкшынуны үткәрүне (кагыйдә буларак, стентлау белән) (алга таба – ЧКВ) башкару мөмкин булмаганда, симптомнарның озынлыгы 12 сәгатьтән дә кимрәк булган ОКС белән пациентларга диагноз куелганнан соң 120 минут эчендә үткәрү.

2. Тромболитик терапияне, каршы күрсәтмәләре булмаганда, ЧКВ үткәрү мөмкин булмаганда һәм ИМпST (куркыныч астында миокардның зур зонасы һәм/яки гемодинамик тотрыксызлык) белән аерым пациентларда трансмураль ишемиянең симптомнары һәм билгеләре (ЭКГда ST сегменты күтәрелеше) сакланганда, үлем куркынычын киметү өчен, симптомнар барлыкка килү вакыттан 12-24 сәгатьтән соң үткәрү.

3. Тромболитик препаратларны кертү каршы күрсәтмәләр булмаганда диагноз куелганнан соң 10 минут эчендә һәм күрсәтмәләр булган очракта һәм каршы күрсәтмәләр булмаган очракта, госпитальгә кадәрге чорда башланырга тиеш.

4. ТЛТга каршы абсолют күрсәтмәләр:

– элегрәк кичерелгән геморрагик инсульт яки билгесез этиологияле баш мие кан әйләнеше бозылу;
– ишемик инсульт алдагы 6 айда;
– үзәк нерв системасының зарарлануы яки яңа барлыкка килүләр, үзәк нерв системасының артериовенозлы мальформацияләре;
– күптән түгел җитди имгәнү / хирургия тыкшынуы / баш җәрәхәте /ашказаны-эчәк кан агуы (узган ай дәвамында);
– анамнезада геморрагик диатез яки кан агу (менструаль каннан тыш);
– аорта таркалышы (шик астында яки расланган);
– компрессияләнми торган кан тамырлары пункциясе, бавыр биопсиясе, арка мие пункциясе алдагы 24 сәгать дәвамында.

5. ТЛТга карата чагыштырмача чикләүләр:

– транзитор ишемик атака алдагы 6 айда;
– пероральь антиоагулянтларны кабул итү;
– йөклелек һәм бала табудан соң 1 нче атна;
– рефрактер артериаль гипертензия (САД >180 мм рт.ст. һәм/яки ДАД >110 мм рт.ст.);
– каты бавыр авыруы;
– инфекцион эндокардит;
– травматик яки озак вакытлы йөрәк-үпкә реанимациясе;

– жәрәхәт авыруы кискенләшүе.

6. Госпитальгә кадәр яки стационарда ЧКВ үткәрү мөмкинлегеннән башка тромболитик препаратлар алган ИМпST белән пациентлар ПЧКВ-үзәгенә кичекмәстән күчерү.

7. ST сегменты күтәрелеше белән ОКС белән пациентларның реперфузия сайлау




*Искәрмә:*

* медицина хезмәткәре белән беренче контакттан;

** беренче 60 минутта һәм, күп дигәндә, беренче 90 минутта медицина хезмәткәре белән беренче элемтәдән, учреждениеләрдә көн саен тәүлек буе беренчел ЧКВны үтәү программасы белән өстенлек бирү;

*** Госпитальгә кадәрге этапта, диагноз куюдан 10 минут эчендә өстенлек бирү;

**** тотрыклы пациентларның уңышлы ТЛТдан соң 2-24 сәгатьтән соң өстенлек бирелә.

## Б. ST сегменты күтәрелмичә кискен коронар синдром

### 1. ОКСбпST белән пациентларны алып бару стратегиясен сайлау




## В. Инвазив манипуляцияләрне башкару өчен ОКС белән пациентларны сайлап алу алгоритмы

1. Кичектергесез инвазив стратегия (2 сәгать дәвамында) бик югары риск критерийларының берсе (һәм аннан да күбрәк) белән авыручыларга тәкъдим ителә;
2. Иртә инвазив стратегия (24 сәгать дәвамында) югары риск критерийларының берсе (һәм аннан да күбрәк) булган пациентларга тәкъдим ителә;
3. Инвазив стратегия (72 сәгать дәвамында) урта риск критерийларының берсе (һәм аннан да күбрәк) булган пациентларга тәкъдим ителә.

Г. ОКСбпST вакытында тискәре нәтиҗә риск категорияләре

| |
|---|
| Бик югары риск |
| Гемодинамик тотрыксызлык яки кардиоген шок |
| Күкрәк читлегендә дәвам итүче яки кабатланучы авырту, медикаментоз дәвалауга рефрактер |
| Гомер өчен куркыныч аритмия яки кан әйләнеше туктавы |
| Кискен миокард инфарктының механик өзлегүләре (йөрәкнең сул карынчыгы буш стенасы өзелү, карынчыкара бүлгеләрнең өзелүе, папилляр мускулларны өзелү яки митраль клапан капкачлары хорды өзелү) |
| Кискен йөрәк җиткелексезлеге |
| Кабатланучы динамик күчүләр ST сегментының яки T тешендә, бигрәк тә ST сегментының килүче күтәрелеше белән үзгәрешләр |
| Югары риск |
| Миокард инфаркты критерийларына туры килә торган кандагы йөрәк тропонины дәрәҗәсен концентрациясен күтәрү яки кимету |
| Динамик күчүләр ST сегментының яки T тешендә үзгәрешләр (симптомлы яки симптомсыз) |
| GRACE шкаласы буенча баллар суммасы>140 |
| Урта (арадаш) риск |
| Шикәр авыруы |
| Бөер җиткелексезлеге (рСКФ < 60 мл/мин/1,73 м2) |
| Сул карынчык чыгару фракциясе < 40% яки торгын йөрәк җиткелексезлеге |
| Инфаркттан соңгы иртә стенокардия |
| Күптән түгел ЧКВ үткәрү |
| Анамнезда коронар шунтлау операциясе |
| GRACE шкаласы буенча балл суммасы 109дан 140 кадәр балл |
| Түбән риск |
| Югарыда күрсәтелгән критерияләрнең булмавы |

Д. GRACE шкаласы буенча ST сегменты күтәрелешсез ОКС вакытында уңай булмаган нәтиҗә рискын бәяләү

| Риск факторы | Балл |
|---|---|
| Яшь | |
| ≤ 30 | 0 |
| 30–39 | 8 |
| 40–49 | 25 |
| 50–59 | 41 |
| 60–69 | 58 |
| 70–79 | 75 |
| 80–89 | 91 |

| | |
|---|---|
| ≥ 90 | 100 |
| Йөрәк кыскарулар саны (уд/мин) | |
| ≤ 50 | 0 |
| 50–69 | 3 |
| 70–89 | 9 |
| 90–109 | 15 |
| 110–149 | 24 |
| 150–199 | 38 |
| ≥ 200 | 46 |
| Систолик АД (мм рт. ст.) | |
| ≤ 80 | 58 |
| 80–99 | 53 |
| 100–119 | 43 |
| 120–139 | 34 |
| 140–159 | 24 |
| 160–199 | 10 |
| ≥ 200 | 0 |
| Киллип буенча класс | |
| I | 0 |
| II | 20 |
| III | 39 |
| IV | 59 |
| Канда креатинин дәрәҗәсе (мг/дл) | |
| 0–0,39 | 1 |
| 0,40–0,79 | 4 |
| 0,80–1,19 | 7 |
| 1,20–1,59 | 10 |
| 1,60–1,99 | 13 |
| 2,0–3,99 | 21 |
| ≥ 4,0 | 28 |
| Башка факторлар | |
| Китерелгәндә йөрәк туктау | 39 |
| ST сегментының күчеше, T тешенең инверсиясе | 28 |
| Канда миокард некрозы маркерларының югары дәрәҗәсе* | 14 |
| Стационарда үлем рискы | Сумма баллов |
| Түбән (<1%) | ≤ 108 |
| Урта (1–3%) | 109–140 |
| Югары (> 3%) | ≥ 141 |

*Искәрмә:* * әлеге шкала төзегәндә «гадәти» сизгерлекнең йөрәк тропонины кулланылды.

ТР Сәламәтлек саклау
министрлыгының
28.02.2022 № 500 боерыгына
Кушымта № 3

________дән ________ кадәр «________» ДАССУ атналык мәгълүматы
(стационар шартларда медицина ярдәме күрсәтүче, үз структурасында ПЧКВ-үзәк булмаган медицина оешмалары өчен)

| | | Хисап атнасында | Үсүче нәтиҗә белән |
|---|---|---|---|
| 1. | ОКС белән госпитализацияләнгән, шуларның | | |
| 1.1. | ST сегменты күтәрелеше белән | | |
| 1.2. | ST сегменты күтәрелеше булмаган | | |
| 2. | ОКС өзлегүләр | | |
| 3. | ЧКВга күчерелгән | | |
| 4. | Күчерелүгә кичектерелгән | | |
| 5. | ОКС белән чыгарылган | | |
| 6. | Үлем | | |

ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының
28.02.2022 № 500
боерыгына
Кушымта № 4

______дән ______кадәр «________» ДАССУ айлык мәгълүматы
(ПЧКВ-үзәкләр өчен)

| | Барлыгы кергән (кеше) | Кергәннәрдән үлүчеләр саны (кеше) | Корона-роангиография үткәрелгән сан (кеше) | Стентлау үткәрелгән сан (кеше) | КШга җибәрелгән кеше саны | Тромболизис үткәрелгән (кеше) | | Тромболизис+ стентлау үткәрелгән авырулар саны |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Госпи-тальгә кадәр | стацио-нарда | |
| ST сегменты (Q теше белән) күтәрелеше белән миокард инфаркты | | | | | | | | |
| ST сегменты (Q теше белән) күтәрелешсез миокарда инфаркты | | | | | | тутырмаска | | |
| Тотрыксыз стенокардия | | | | | | тутырмаска | | |
| Барлыгы | | | | | | | | |

Шул исәптән  Татарстан Республикасы районнарынан китерелгән

| | Барлыгы кергән (кеше) | Кергәннәрдән үлүчеләр саны (кеше) | Корона-роангиография үткәрелгән (кеше) | Стентлау үткәрелгән сан (кеше) | КШга җибәрелгән кеше саны | Тромболизис үткәрелгән (кеше) | | Тромболизис+ стентлау үткәрелгән авырулар саны |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Госпитальгә кадәр | стационарда | |
| ST сегменты (Q теше белән) күтәрелеше белән миокард инфаркты | | | | | | | | |
| ST сегменты (Q теше белән) күтәрелешсез миокарда инфаркты | | | | | | тутырмаска | | |
| Тотрыксыз стенокардия | | | | | | тутырмаска | | |
| Барлыгы | | | | | | | | |

202_ елның 1 гыйнварына кардиологик койкалар саны: __ койка, алга таба хисап чорына __ койка

202_ елның 1 гыйнварына сырхауханәләрдә эшләүче кардиологлар саны: __, соңгы хисап чорында _____ кардиологлар

202_ елның 1 гыйнварына стационарларда эшләүче кардиологлар саны: __, соңгы хисап чорында _____ кардиологлар

ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының 28.02.2022 № 500 боерыгына
Кушымта № 5

______дән ______кадәр ОКСдан үлүче пациентлар турында «________» ДАССУ айлык мәгълүматы

| № | ФИО | Туу датасы | Госпита-лизация датасы | Язылу буенча адрес | Кем җибәргән | Җибәргән учрежде-ние диагнозы | Соңгы диагноз | Полик-линика № | Эпид. анамнез | Диспансерлаш-тыру/диспансер күзәтүе турында белешмәләр | Искәрмәләр |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

ТР Сәламәтлек саклау
министрлыгының
28.02.2022 № 500
боерыгына
Кушымта № 5

_________ числога «__________» ДАССУның Татарстан Республикасы халкына югары технологияле кардиохирургия ярдәме күрсәтү буенча айлык

| КАГ/КТ-КАГ га планлы тәртиптә җибәрелгән | фактик үтәлгән коронарография | Планлы КАГ көтү битендә (кеше) | Планлы КАГ нәтиҗәләре буенча ЮТМЯ күрсәтелгән | | АКШ га көтү битендә (кеше) (агымдагы айга) |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | АКШ (кеше) | Коронар артерияләрне стентлау (кеше) | |